ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

19.07.2021 г. Заинск № 470

**«Адреслы матди ярдәм күрсәтү буенча комиссия төзү турында» 2014 елның 12 декабрендәге 2844 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Авыр тормыш шартларында калган затларга социаль ярдәмнең адреслы формаларының нәтиҗәлелеген арттыру, гражданнарның матди ярдәм күрсәтү турында гаризаларын карауны камилләштерү максатларында, Зәй муниципаль районы Уставының 45 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. «Адреслы матди ярдәм күрсәтү буенча комиссия төзү турында» 2014 елның 12 декабрендәге 2844 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән расланган (2015 елның 17 ноябрендәге 1907 номерлы, 2016 елның 17 октябрендәге 2279 номерлы, 2016 елның 24 ноябрендәге 2687 номерлы, 2018 елның 01 февралендәге 157 номерлы, 2018 елның 02 апрелендәге 509 номерлы, 2018 елның 10 маендагы 739 номерлы, от 22.06.2018 елның 22 июнендәге 1023 номерлы, 2019 елның 14 февралендәге 51 номерлы, 2019 елның 20 мартындагы 141 номерлы, 2019 елның 17 июнендәге 313 номерлы, 2019 елның 09 августындагы 423 номерлы, 2020 елның 16 мартындагы 100 номерлы, 2020 елның 21 октябрендәге 466 номерлы, 2020 елның 23 декабрендәге 596 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) гражданнарга адреслы матди ярдәм күрсәтү буенча нигезләмәнең 3.1. пунктының 4 абзацына үзгәреш кертергә: «- елына 30 000 сумга кадәр» сүзләрен «- елына 100 000 сумга кадәр» сүзләренә алмаштырырга.
2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

3. Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының оештыру бүлегенә әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары А.В. Чапковка йөкләргә.

**Башкарма комитет**
**җитәкчесе** **Э.Э. Галеев**

И.В.Шакирзянова
7 07 66
Юрист
7 10 27